ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**“ 03 ” март 2016 ел** **№ 226**

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 431 статьясы, «Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының 2016 елның 22 февралендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына (алга таба - регистр) кертү буенча башкарма комитетның (норматив характердагы нигезләмәләр булган) норматив характердагы күрсәтмәләрен, карарларын күрсәтелгән законнарда билгеләнгән тәртиптә, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын җыю һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрү буенча үзара эшчәнлек регламентын билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны билгеләргә.

2. Башкарма комитетның муниципаль норматив хокукый актларын һәм алар турында белешмәләрне регистрга кертү өчен җибәрүгә җаваплы зат итеп

башкарма комитетның оештыру-гомуми бүлегенең баш белгече Ф.И.Никашинаны билгеләргә.

3. Әлеге карарның 2 пунктында каралган баш белгеч вакытлыча булмаган очракта, вәкаләтләрнең Арча муниципаль районының административ комиссиясе баш белгече Л.М. Таһировка йөкләнүен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин